| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 27 декабре № 42/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча «Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды» ДБУ биргән материалларны карап, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча 2024 елның 17 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2024 елның 18 декабрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 7 һәм 29 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2022 елның 30 июнендәге 20/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә электрон чыганактагы кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен (кертелгән үзгәрешләр белән) территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында (www.droganoye.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Алешкин-Саплык авыл җирлеге бүлегендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров